**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2016 елның 3 октябре № 57

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында инициативаны тәкъдим итү турында» 2016 елның 9 сентябрендәге 127 номерлы карары белән күрсәтелгән, халык фикерен белдереп, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Советы, Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карары:**

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турындагы инициативаны тәкъдим итү турында» 2016 елның 9 сентябрендәге 127 номерлы карары белән күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләрен карта-схема нигезендә үзгәртүгә ризалык бирергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча Нижневязовск шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә мөмкин: ТР, Зеленодольск районы, Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 (Башкарма комитет бинасы янында); Кочемировская ур., 2а («ЮСОН» кибете янында); Беренче Май урамы (вокзал яны мәйданы); Шоссейная урамы («Диана» кибете янында); Шоссейная урамы («Рубин» кибете янында).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Карамалы Тау шәһәр җирлеге башлыгы, Совет рәисе Ф. н.Шәмсиевкә йөкләргә.

**Карамалы Тау районы Башлыгы**
**шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Ф.Н. Шәмсиев**